***Харисов Фираз Фахразович***
***Сәгъдиева Илсияр Миргазизовна***
Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

# ТАТАР ТЕЛЕНӘ ЧИТ ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘТКӘНДӘ, КОМПЬЮТЕР ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Данная статья посвящена проблеме формирования знаний, умений и навыков при обучении татарскому языку и литературе с помощью компьютерных технологий, т.е. формированию компетентной языковой личности. Процесс обучения будет успешным, если знания, умения и навыки усваиваются учащимися в строгой последовательности, соблюдая известные дидактические и лингвометодические принципы.*

**Ключевые слова:** *урок, воспитательный процесс, методы, тесты, познание, компьютерные технологи.*

*This article is devoted to the formation of knowledge and skills in teaching the Tatar language and literature with the help of computer technology, i.e. the formation of a competent person in language. The learning process will be successful if the knowledge and skills of students are digested in sequence, following the well-known didactic and linguistic and methodological principles.*

**Key words.** *Lesson, educational process, methods, tests, knowledge, computer technology.*

Хәзерге мәгариф системасын компьютер технологияләреннән башка күз алдына да китереп булмый. Яңа Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты дәресләрдә заманча белем бирү технологияләрен куллануның мөһимлегенә аеруча басым ясый. Шулай булгач, татар теле һәм әдәбияты укытучылары да бу мөмкинлектән киңрәк файдаланырга тиеш.

Бу уңайдан укытучы һөнәре – шактый катлаулы һәм зур җаваплылык таләп итә торган хезмәт. Дәрес кызыклы, мавыктыргыч һәм нәтиҗәле булсын өчен, ул фәнни-методик нигезгә корылып, төрле принцип, метод, алым һәм чара яки яңа технологияләрне кулланып уздырылырга тиеш. Шулай булганда гына башка телдә сөйләшүче укучыларда татар теленә һәм әдәбиятына карата мәхәббәт тәрбияләнә ала. Иң мөһиме – заманча дәрес уздыру өчен, укытучы үзе мәгълүмати-аралашу технологияләрен куллана белергә, әлеге эшкә фәнни-методик һәм психологик яктан әзер булырга тиеш [Хуҗиәхмәтов, 2015: 112].

Мәгълүм булганча, дәрес – белем бирү вакытында укыту-тәрбия системасын оештыруның иң мөһим формаларыннан санала. Ул укытучы һәм укучының бергә системалы һәм эзлекле эшләвендә чагылыш таба. Укучылар дәрестә активлык күрсәтеп, зур теләк белән эшләгәндә генә белемнең сыйфаты югары була. Аңа дәресне түбәндәгечә оештырганда ирешеп була:

- максат һәм бурычларны төгәл һәм аңлаешлы итеп билгеләү;
- тел һәм сөйләм материалын уйлап, укучыларга дифференциацияле якын килеп сайлау;
- татар теле һәм әдәбияты, чиктәш фәннәрдәге яңалыкларны истә тотып, дәрестә заманча технологияләрдән киң файдалану;
- укучыларда белем, осталык һәм күнекмәләрне этаплап, системалы рәвештә булдыру;
- дәресне яңа Стандартта каралган системалы-эшчәнлекле юнәлеш буенча уздыру;
- укучыларда ныклы универсаль уку гамәлләрен булдыру һәм аларны киләчәктә гамәли эштә кулланырга өйрәтү һ.б.

Өйрәнелә торган телгә мәхәббәт уяту өчен, укытучы балаларны да һәм үзе укыткан фәнне дә бертигез яратырга тиеш. Шулай булганда гына, ул куелган максат-бурычларына тулысынча ирешә ала һәм бу гамәл үтәлгәндә, дәрес тә кызыклы һәм нәтиҗәле үзачак.

Хәзер Татарстан мәктәпләрендә компьютер технологияләре актив кулланылышка керде һәм ул телгә өйрәтүнең мөһим чараларыннан санала. Компьютер технологиясе – укучыга мәгълүматны компьютер мөмкинлекләрен файдаланып әзерләү һәм тапшыру процессы ул [Сулейманов,1999: 125]. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – бүгенге көндә методиканың мөһим бурычы, чөнки ул программада каралган сөйләм һәм тел материалын адресатка вакытында җиткерергә ярдәм итә, балаларда дәрескә карата кызыксыну уята, белем алу эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыра.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә компьютер технологияләрен кулланып нинди эшләр башкарып була соң? Кайберләрен генә санап китик:

- өй эшен тикшергәндә, яңа материалны аңлатканда, сөйләм ситуацияләрен модельләштергәндә;
- ике телне (татар һәм рус телләрен) чагыштырып өйрәткәндә, тел күренешләрен аңлатканда;
- электрон дәреслекләр белән эшләгәндә;
- укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләргә ия булуларын тикшергәндә;
- Интернет челтәрендәге татар сайтларыннан темага кагылышлы мәгълүмат эзләгәндә һ.б. [Харисов, 2015: 219-220].

Рус телендә сөйләшүче укучыларны татар теленә өйрәткәндә, югары зәвык белән эшләнгән презентацияләр куллану дәрескә аеруча зур җанлылык өсти, аларның тел белән кызыксыну дәрәҗәсен үстерә. Презентацияләрне, аерым слайдларны дәреснең төрле этапларында кулланырга кирәк (өй эшен тикшергәндә, яңа материалны аңлатканда, проблемалы ситуацияләр тудырганда, дәрес барышында белемнәрне тикшергәндә, өй эше биргәндә

һ.б.). Болай эшләгәндә, укучыларның белем һәм күнекмәләр дә ныклырак була [Kharisova, 2015: 156].

Компьютер технологияләрен укучыларны ял иттергәндә файдалану да уңышлы була, чөнки аның ярдәмендә хәрәкәтне күрсәтергә, тавышны бирергә була. Шул хәрәкәтләрне кулланып, табышмак, мәкальләрне искә төшерү дә татар телен өйрәнүне актуальләштерә ала. Тавышны куллану, рус телендә сөйләшүче укучыларны татар авазларын әйтергә өйрәткәндә дә ярдәм итәчәк.

Шулай ук компьютер технологияләрен укучыларның танып-белү эшчәнлекләрен активлаштырганда, мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстергәндә файдаланып була; тел һәм сөйләм өлкәсенә караган белем, осталык һәм күнекмәләрнең формалашу дәрәҗәсен билгеләгәндә яки тест формасындагы биремнәрне компьютерда үтәгәндә, укучылар үзләре дә белемнәрен тикшерә һәм бәяли алалар.

Димәк, компьютер технологиясен кулланып дәресне кызыклы, мавыктыргыч итеп үткәререп була икән. Ул аны җанландырып җибәрә, төрле фонетик, лексик, грамматик уеннар куллану мөмкинлеген тудыра. Мондый дәресләр балаларның сүзлек составын баету, аралашу күнекмәләрен булдыру, логик фикер йөртү сәләтләрен үстерү өчен дә кирәк. Укытучы аларның кайберләрен укучыларга иҗади өй эше итеп тә бирә ала.

**Әдәбият**


1. Сулейманов, Д.Ш. Татарский язык и новые информационные технологии / Д.Ш. Сулейманов // Языковая ситуация в РТ: Состояние и перспективы. – Казань, 1999. – Часть 1. – С. 124-132.
2. Харисов, Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.Ф. Харисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 302 б.
3. Хуҗиәхмәтов, Ә.Н. Заманча уку-укыту технологияләре: югары һәм махсус урта уку йортлары өчен лекцияләр курсы / Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. – Казан: КФУ, 2015. – 369 б.
4. Kharisova, C.M., Kharisov, F.F., Shakirova, G.R. Psycho-pedagogical basis of mother-tongue education Journal of Language and Literature // Volume 6, Issue 3, 2015. – P. 155-158.



***Харисов Фираз Фахразович***

***Харисова Чулпан Мухаррамовна***

Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан


## КАЗАН ЛИНГВОМЕТОДИКА МӘКТӘБЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ВӘКИЛЕ


*Статья посвящена жизни, научно-педагогической и методической деятельности одного из ведущих лингвометодистов нашей страны в области преподавания русского языка в национальной школе, автору более чем 600 научно-методических трудов, доктору педагогических наук,*